**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

«11» февраль 2022г. с. Тюлячи № 14

Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын эшләү турында

Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 10 февралендәге 53 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын эшләүгә керешергә.
2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан төзелгән техник бирем нигезендә проектны эшләүне гамәлгә ашырырга.
3. Теләче авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектына заказчы итеп Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.
4. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24, 25, 31 статьялары таләпләре нигезендә проектны карау, килештерү, раслауны үткрергә.
5. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин